# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ

**(IV чакырылыш)**

IV чакырылышның чираттан тыш утырышы

# КАРАРЫ

25 июнь 2025 ел №35 Урыссу ш.т.б.

Муниципаль районнарның бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияне 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына физик затлар керемнәренә салымнан Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджетына күчерүләрнең өстәмә нормативы белән алмаштыруны килештерү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 138 статьясындагы 5 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар итте:

1. Муниципаль районнарның бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрне 2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына физик затлар керемнәренә салымнан Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджетына күчерүләрнең өстәмә нормативы белән алмаштыруны килештерергә.

2. Әлеге карарның күчермәсен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан

Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча рәсми бастырып чыгару юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының Бюджет, салымнар, инвестицияләр һәм эшкуарлык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин